ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИМОШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№16 08 .02.2021

Иске Тимошкино авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 11 мартындагы 90 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Тимошкино авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 11 мартындагы 90 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 15 пунктның 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** «Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты житәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар.»

**1.2. 3 пунктның 4 пунктчасында 20 бүлегендә** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

**1.3. 3 пунктның 6 пунктчасында 20 бүлегендәге** «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ» сүзләренә алыштырырга.

**1.4 34 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:** «муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында

мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatar.ru) һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам

Аксубай муниципаль районы
Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: П.А.Мулеева